ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина,,д.33, с.Каракашлы 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт, Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-21, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2024 ел № 14

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсе нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- Кәрәкәшле торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы чишмәне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында балалар өчен уен мәйданчыгын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү (зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерү (чүп үләннәрен юкка чыгару, корыган агачларны, куакларны кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетына Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев